КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 18 декабрь г.Казань № 1060

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 15 апрель, 187 нче; 2006 ел, 2 август, 396 нчы; 2007 ел, 12 октябрь, 549 нчы; 2009 ел, 2 март, 117 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 657 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1036 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 534 нче; 2011 ел, 25 октябрь, 887 нче; 2013 ел, 18 март, 178 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 858 нче; 2014 ел, 7 февраль, 70 нче; 2014 ел, 20 май, 336 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 970 нче; 2015 ел, 5 июнь, 422 нче; 2015 ел, 9 декабрь, 929 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче; 2016 ел, 14 июль, 480 нче; 2016 ел, 27 июль, 517 нче; 2017 ел, 24 октябрь, 805 нче; 2018 ел, 4 июль, 552 нче; 2018 ел, 26 ноябрь, 1052 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Министрлык түбәндәгеләр белән үзара хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән мәгариф белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.05);

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән табигать ресурсларыннан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.06);

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән билгеләнгән тәртиптә хезмәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13*);

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән мәгълүматлаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15);

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән сәнәгать белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.01);

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән авыл хуҗалыгы белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.02);

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән шәһәр төзелеше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.05);

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән билгеләнгән тәртиптә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.03.03);

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән билгеләнгән тәртиптә транспорт комплексы белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.03);

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән сәламәтлек саклау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.02);

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән мәдәният (шул исәптән сәнгать, кинематография, тарихи-мәдәни мирасны саклау һәм алардан файдалану) өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу, төрле диндәге дини берләшмәләр арасында үзара аңлашуны һәм түземлелекне ныгытуга булышлык күрсәтү функциясен гамәлгә ашырганда (04.03);

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.04);

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү (04.07) һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә дәүләт ярдәмен тәэмин итү (01.16) функцияләрен гамәлгә ашырганда;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән социаль-икътисадый программалар эшләү функциясен гамәлгә ашырганда (01.01);

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы белән урман фондыннан файдалану, саклау, яклау һәм урманнарны торгызу өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу функцияләрен гамәлгә ашырганда (01.06.04);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норматив документлар әзерләү эшчәнлеген яраштыру (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килү-килмәвен тикшерүдә тоту) (02.04.01);

республика башкарма хакимият органнарының норматив хокук актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.03).»;

4.1.12 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә товар базарларында конкуренцияне үстерү буенча максатлар һәм бурычлар өстенлекләрен тәэмин итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин